3.1. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясындагы 2 пункты нигезендә чираттагы финанс елыннан башлап гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган муниципаль программалар җирле администрация тарафыннан билгеләнгән срокларда расланырга тиеш. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге дәрәҗәсендә кабул ителә торган муниципаль программаларга карата мондый срок Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенең 1.7 пунктында билгеләнгән, аның нигезендә чираттагы финанс елы башыннан гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган муниципаль программалар агымдагы финанс елының 1 июленә кадәр расланырга тиеш.

Югарыда китерелгән хокукый нормаларның турыдан-туры эчтәлегеннән чыгып, шуны әйтергә кирәк: «2017—2019 елларга Казан шәһәрендә "Электрон Казан" мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне үстерү» муниципаль программасы 2017 елдан башлап үзенең гамәлгә ашырылуын күздә тотканлыктан, Башкарма комитетның аны раслаган карары да 2016 елның 1 июленнән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш. Димәк, дәгъва белдерелә торган карарның 2016 елның 21 декабрендә кабул ителү факты үзеннән-үзе аны кабул иткәндә Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенең 1.7 пунктында каралган срок бозылуга юл куелган булуын раслый.

Шуның белән бергә, Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк дип саный.

Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2014 елның 30 сентябрендәге 09-05-05/48843 номерлы хаты белән җибәрелгән дәүләт (муниципаль) программалары нигезендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларын һәм җирле бюджетларны төзү һәм үтәү буенча методик тәкъдимнәрнең 6 пунктыннан аңлашылганча, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 6 статьясы, шулай ук 84, 85, 86 статьялары нигезләмәләре буенча, чыгым йөкләмәләре тиешле бюджетлардан акча алучыларны аларда конкрет күрсәтеп — физик яисә юридик затлар (күрсәтелгән затларның категорияләрен), гавами-хокукый берәмлекләрне, бирелә торган ресурс күләмнәрен яисә мондый күләмнәрне билгеләү тәртибен күрсәткән законнарны, башка норматив хокукый актларны кабул итү нәтиҗәсендә барлыкка килә; муниципаль программалар үзләреннән-үзләре чыгым йөкләмәләрен булдырмыйлар, чөнки алар күрсәтелгән таләпләргә туры килмиләр, шул исәптән тиешле бюджетлардан акча алучыларны конкрет билгеләмиләр. Шуңа бәйле рәвештә муниципаль программаларны алдан кабул итүгә һәм аларга үзгәрешләр кертүгә юнәлдерелгән хокукый җайга салуны билгеләү бюджет турындагы норматив хокукый акт нигезендә бюджет чыгымнарын планлаштыруга бәйле.

«2017—2019 елларга Казан шәһәрендә "Электрон Казан" мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру чыгымнары Казан шәһәр Думасының 2017 елның 12 апрелендәге 3-15 номерлы карары белән 2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның планлы чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кертелгән.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды дәгъва белдерелә торган карарны бу максатлар өчен билгеләнгән сроктан тыш кабул итү бюджет акчаларын хокуксыз сарыф итү өчен шартлар тудырмаган, дип саный. Моннан тыш, Башкарма комитетның шикаять белдерелә торган карарын кабул итү тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тану каралучы 1 нче ярдәмче программа, шулай ук тулаем муниципаль программа кысаларында инде гамәлгә ашырылган чараларның законлылыгын шик астына куярга мөмкинлек бирер иде. Мондый нәтиҗә Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы нигезендә Татарстан Республикасының конституциячел корылышын, кешенең һәм гражданның төп хокукларын һәм ирекләрен яклау, Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасының хокукый системасында өстенлеген һәм аның бөтен территориясендә турыдан-туры гамәлдә булуын тәэмин итү кебек конституциячел суд эшләрен башкару максатларына каршы килер иде.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге эштә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының дәгъва белдерелә торган карарын аны кабул итү тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып кала. Моның белән Казан шәһәренең җирле администрациясеннән, Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм әлеге Карарны исәпкә алып, муниципаль программаларны кабул итү срогы турындагы таләпнең үтәлешен чынлыкта тәэмин итү бурычы алынмый.

3.2. Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясы (өченче өлеш) һәм Россия Федерациясе Конституциясенең 15 статьясы (3 өлеш) нигезендә, кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы норматив хокукый акт, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган булса, кулланыла алмый.

Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, дәүләт исеменнән норматив хокукый актны гавами хакимиятнең компетентлы органы тарафыннан халыкка җиткерү таләбе хокукый билгеләнешнең гомумтанылган принцибына бәйле, аның нигезендә дәүләтнең һәм шәхеснең мөнәсәбәтләре билгеләнә һәм җәмәгатьчелеккә хәбәр итү әлеге норматив хокукый актның кабул ителүе һәм бәян ителгән тулы текстының гамәлгә кертелергә тиешлеген аңлата. Шул очракта гына аның гамәлдә булуы кагыла торган затларга законны белмәү аны бозган өчен җаваплылыктан азат итми дигән гомумхокукый презумпция кагыла. Норматив

хокукый актның гамәлдә булуы яисә булмавына карата билгесезлек аны саклауда, үтәүдә һәм кулануда бертөрлелекне тәэмин итә алмый һәм, димәк, хокук куллану практикасында каршылык китереп чыгара, аны зыянлы максатта һәм башбаштакланып файдалану мөмкинлеген тудыра, конституциячел хокукларны һәм ирекләрне яклау гарантияләрен киметә, тигезлек һәм хокук өстенлеге принципларын бозуга китерә (2012 елның 27 мартындагы 8-П номерлы Карар).

Татарстан Республикасы Конституция суды бу конституциячел күрсәтмә кеше һәм граждан хокукларын, ирекләрен яклау гарантияләренең берсе булып тора һәм ул императив характерга ия дип берничә тапкыр билгеләп үтте (2006 елның 7 мартындагы 19-П номерлы һәм 2012 елның 21 февралендәге 47-П номерлы карарлар).

Муниципаль норматив хокукый актларны рәсми бастырып чыгару тәртибе «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре белән регламентланган, 44 статьяның 1 өлешендәге 6 пункты белән үзара бәйләнештә 47 статьяның 2 һәм 3 өлешләре эчтәлегеннән күренгәнчә, җирле үзидарә органнарының кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы һәм федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булмаган норматив хокукый актлары, бары тик тиешле муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнгән тәртиптә аларның тулы тексты басылып чыккан очракта гына, гомуми белешмә өчен рәсми рәвештә басылып чыккан дип танылырга мөмкин, алар тарафыннан шул исәптән кабул итү (басылу), рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм муниципаль хокукый актлар үз көченә керү тәртибе билгеләнергә тиеш.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 63 статьясындагы өченче абзацы нигезләмәләре буенча Башкарма комитет тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актлар кул куелган көннән алып ун көн эчендә рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш. Шуңа бәйле рәвештә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының дәгъва белдерелә торган 1 нче ярдәмче программа расланган 2016 елның 21 декабрендәге 5251 номерлы карары, кабул ителгәннән соң, 2016 елның 30 декабреннән дә соңга калмыйча, һичшиксез рәсми бастырып чыгарылырга тиеш иде. Шул ук вакытта ул Казан шәһәре Думасының «Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару турында» 2006 елның 17 февралендәге 15-6 номерлы карары белән муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару чыганагы сыйфатында билгеләнгән «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең документлар һәм хокукый актлар җыентыгы»ның 2017 елның 9 мартындагы 8 номерында басылып чыккан.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 63 статья-

сындагы тугызынчы абзацы нигезендә кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, алар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керүен исәпкә алып, Башкарма комитетның шикаять белдерелә торган карары, шулай ук аның тарафыннан расланган «2017—2019 елларга Казан шәһәрендә "Электрон Казан" мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне үстерү» муниципаль программасы кебек үк, 1 нче ярдәмче программа да аның кысаларында гамәлгә ашырыла, кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына турыдан-туры кагылышлы норматив хокукый акт буларак, бары тик рәсми басылып чыкканнан соң, ягъни 2017 елның 9 мартыннан гына кулланылырга тиеш.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция суды дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны билгеләнгән срокны бозып бастырып чыгару үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләрнең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуны күрсәтми һәм рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча аны Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тану өчен һичшиксез һәм җитәрлек нигез булып тормый, ә бары тик аның үз көченә керү срогының соңрак булуын аңлата, дигән нәтиҗәгә килә.

4. Татарстан Республикасын хокукый дәүләт дип игълан итеп, Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасына кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен иң зур хәзинә буларак тану, үтәү һәм яклау бурычын йөкли (1 статьяның беренче өлеше һәм 2 статья). Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституциясе Россия Федерациясе гражданнары Татарстан Республикасы территориясендә Татарстан Республикасы Конституциясе, халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары нигезендә барлык хокукларга һәм ирекләргә ия һәм бертигез бурычлы, дип беркетә (22 статья); Татарстан Республикасы кулланучы мәнфәгатьләрен яклый һәм аның хокукларын яклау буенча иҗтимагый эшчәнлекне хуплый (51 статья). Күрсәтелгән конституциячел нигезләмәләр шул исәптән җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган норматив хокукый актларның эчтәлеген һәм мәгънәсен билгелиләр.

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы нигезләмәләре буенча муниципаль программа муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсешенең бурычлары, башкару сроклары, башкаручылары, ресурслары буенча һәм максатларга иң нәтиҗәле ирешүне һәм бурычларны хәл итүне тәэмин итүче планлаштырылган чаралар комплексын үз эченә алган стратегик планлаштыру документы булып тора (35 пункт).

Дәгъва белдерелә торган 1 нче ярдәмче программа нигезләмәләренең эчтәлегеннән күренгәнчә, ул «Имин шәһәр» комплексын төзү һәм үстерүнең беренче чираттагы чараларын гамәлгә ашыруны, «Имин шәһәр» комплексы сегментларын алга таба

гамәлгә керту максатларыннан тотрыклы инфраструктура булдыруга юнәлтелгән оештыру-техник чаралар башкаруны күздә тота. Вакыйгаларны һәм инцидентларны мониторинглауга, ачыклауга, идентификацияләүгә һәм фаразлауга юнәлтелгән аппарат-программа чараларын, мәгълүмат системаларын, техник чараларны гамәлгә керту һәм куллану хисабына җәмәгать куркынычсызлыгы, хокук тәртибе һәм яшәү тирәлеге иминлегенең гомуми дәрәҗәсен күтәрү 1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның максаты булып тора. 1 нче ярдәмче программа белән беркетелгән бурычларны хәл итү кысаларындагы чараларның берсе — күпфатирлы йортларда һәм алар биләп торган җир кишәрлекләрендә видеокүзәтү үсеше, ул булган вакыйгаларны кисәтү, ачыклау һәм идентификацияләү, элегрәк булган вакыйгалар динамикасын торгызуга юнәлдерелгән программа-аппарат чаралары комплексын үз эченә ала. 1 нче ярдәмче программаның турыдан-туры эчтәлегеннән күренгәнчә, видеокүзәтү оештыру планлаштырылган күпфатирлы йортларның саны якынча һәм аңа ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Шуның белән үзенең хокукый табигате һәм турыдан-туры эчтәлеге буенча 1 нче ярдәмче программаның шикаять белдерелә торган нигезләмәләре бары тик тәкъдим итү характерындагы, күпфатирлы йортларда видеокүзәтү оештыруга бердәм оештыру-техник якын килүне гамәлгә ашыру механизмын тәэмин итүгә юнәлдерелгән гомуми күрсәтмәләрне генә күздә тота. Шул ук вакытта өстенлекле тәртиптә видеокүзәтү объектлары булып күпфатирлы йортның яки бер төркем күпфатирлы йортларның йорт яны территориясе тора, шул исәптән барлык кварталга керү һәм чыгу урыннарын, халык күпләп була торган территорияләрне (балалар, уен, спорт мәйданчыклары), автотранспорт парковкаларын, каты көнкүреш калдыклары җыю нокталарын, бер төркем күпфатирлы йортларның гомуми панорамасын видеоконтрольдә тоту тәэмин ителә.

Россия Федерациясе Торак кодексының 36 статьясы нигезендә күпфатирлы йорттагы фатир өлешләрен тәшкил итмәгән һәм әлеге йортта бердән күбрәк урынга хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән урыннар, аерым милекчеләрнеке булмаган һәм әлеге йортта урын милекчеләренең социаль-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән башка биналар, аларның ялын, мәдәни үсешен, балалар иҗатын, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүләрен һәм моңа охшаш башка чараларны оештыру өчен билгеләнгән бүлмәләрне дә кертеп, шулай ук әлеге йорт урнашкан, яшелләндерү һәм төзекләндерү элементлары белән, җир кишәрлеге һәм шушы йортка хезмәт күрсәтү, аны эксплуатацияләү һәм төзекләндерү өчен билгеләнгән һәм шушы җир кишәрлегендә урнашкан башка объектлар күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми өлешле милек хокукындагы гомуми мөлкәте булып тора.

Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясындагы 1.1 өлеше нигезендә күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләренең гомуми милкен тиешле тәртиптә тоту

Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә башкарылырга тиеш һәм күпфатирлы йортның ышанычлылыгына һәм иминлегенә, гражданнарның тормыш һәм сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтнең иминлегенә һәм башкаларга карата таләпләрне үтәүне тәэмин итәргә тиеш. Уртак милекне карап тотуның хокукый шартлары Россия Федерациясе Торак кодексының 39 статьясындагы өченче өлеше буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта уртак милекне карап тоту кагыйдәләре белән билгеләнгән, алар нигезендә биналар хуҗалары уртак милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча гамәлләрне мөстәкыйль башкарырга яки күпфатирлы йорт белән идарә итүнең сайланган ысулын исәпкә алып, уртак милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару өчен башка затларны җәлеп итәргә хокуклы (12 пункт), шулай ук гомуми җыелышта хезмәтләр һәм эшләр исемлеген, аларны күрсәтү һәм башкару шартларын, аларны финанслау күләмен расларга тиешләр (17 пункт).

Әлеге эшкә карата китерелгән хокукый җайга салу эчтәлегеннән күренгәнчә, күпфатирлы йортны видеокүзәтү системасы белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү мондый йорттагы урыннар милекчеләренең аерым хокукы булып торуын аңлата. Шул ук вакытта видеокүзәтү системасын кертү турындагы карар, видеокүзәтү хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм аның өчен түләү күләме кебек үк, әлеге милекчеләрнең гомуми җыелышында билгеләнгән тәртиптә кабул ителергә һәм тиешле беркетмә белән рәсмиләштерелергә тиеш. Россия Федерациясе Торак кодексының 44 статьясындагы 1 өлешенең һәм 46 статьясындагы 5 өлешенең үзара бәйле нигезләмәләре мәгънәсе буенча күпфатирлы йорт белән идарә итү органы буларак күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары күпфатирлы йорттагы барлык урыннар милекчеләре өчен, шул исәптән тавыш бирүдә катнашмаган милекчеләр өчен дә мәҗбүри булып тора.

Мондый алым Россия Федерациясе Югары Суды тәҗрибәсенә туры килә, ул, «видеокүзәтү» хезмәте өчен күпфатирлы йортта урын милекчеләренә түләү исәпләүнең законлылыгы турындагы мәсьәләне карап, күпфатирлы йортта видеокүзәтү хезмәтләренең үзенчәлеге аларның аерым милекчеләргә индивидуаль күрсәтелүен күздә тотмый дигән нәтиҗәгә килде; видеокүзәтү системасын урнаштыру гомуми мөлкәтне тиешле тәртиптә тотуга, урыннар милекчеләренең иминлеген һәм мөлкәтен саклауны тәэмин итүгә, ягъни күпфатирлы йорт белән идарә итүгә турыдан-туры юнәлдерелгән хезмәт булып тора (2017 елның 20 июнендәге 11-КГ17-13 номерлы Билгеләмә).

Шулай итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5251 номерлы карары белән расланган «2017—2019 елларга Казан шәһәрендә "Электрон Казан" мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне

үстерү» муниципаль программасының 1 нче ярдәмче программасы, аның хокукый статусын һәм эчтәлеген исәпкә алып, гражданнарга күпфатирлы йортларны видеокүзәтү системасы белән тәэмин итү бурычын йөкләми, күпфатирлы йортларда видеокүзәтү системасын урнаштыру һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтүгә кагылышлы мөнәсәбәтләрне императив тәртиптә җайга сала торган нинди дә булса нигезләмәләрне үз эченә алмый, милекчеләрнең үз ихтыярларыннан башка, финанслау күпфатирлы йортлардагы торак урыннарның милекчеләренә йөкләнгән хезмәт күрсәтү форматында видеокүзәтү оештыруны күздә тоткан сервис моделен куллануны күздә тотмый, һәм, димәк, гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләрнең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозмый.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды хокукый нормаларның формаль билгеләнеше аларның җитәрлек дәрәҗәдә төгәллеген күздә тотуын, шуның белән аларны дөрес аңлау һәм бертөрле куллану тәэмин ителүен билгеләп үтәргә кирәк дип саный. Хокукый норманың мәҗбүрилегенә, яки, киресенчә, аның тәкъдим итү характерында булуына карата күрсәтмәнең төгәл булмавы яки төрлелеге, аны хокукый дәүләтнең конституциячел принциплары белән килешми торган ирекле һәм дискриминацион куллануга китерергә мөмкин. Шуңа бәйле рәвештә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына, үзләренең хокукый җайга салуын гамәлгә ашырганда, хокук куллану практикасында аларны төрле мәгънәдә аңлату мөмкинлеген калдырмаслык итеп, хокукый нормаларны формалаштырырга кирәк, бу очракта, аерым алганда, тәкъдим итү характерындагы нормаларга императив форма бирелер иде.

5. Шәхси тормышның кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә хокук Россия Федерациясе Конституциясе белән гарантияләнә (23 статьяның 1 өлеше). Шундый ук гарантияләр Татарстан Республикасы Конституциясенең 36 статьясындагы беренче өлешендә беркетелгән. Әлеге конституциячел нормалар, үз чиратында, Кеше хокукларын һәм төп ирекләрен яклау турындагы конвенциянең 8 статьясындагы беренче пункты нигезләмәләренә туры килә.

Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр күрсәткәнчә, хосусый тормышның кагылгысызлыгына хокук дигәндә, кешегә бирелгән һәм дәүләт тарафыннан гарантияләнгән, үзе турындагы мәгълүматны контрольдә тоту, шәхси, интим характердагы белешмәләрне таратуга каршы тору мөмкинлеген аңлата; «хосусый тормыш» төшенчәсенә кеше тормышының аерым затка караган өлкәсе керә, ул аның үзенә генә кагыла, һәм, әгәр дә ул хокукка каршы булмаса, җәмгыять һәм дәүләт тарафыннан контрольдә тотылырга тиеш түгел (2005 елның 9 июнендәге 248-О номерлы, 2010 елның 26 гыйнварындагы 158-О-О номерлы, 2017 елның 28 сентябрендәге 2211-О номерлы һ.б. билгеләмәләр).

Һәркемнең шәхси һәм гаилә тормышын хөрмәт итү хокукын гарантияләп, Кеше хокукларын һәм төп ирекләрен яклау турындагы конвенциянең 8 статьясы шуның белән бергә, мондый катнашлык законда каралган очракларда һәм демократик җәмгыятьтә милли куркынычсызлык һәм җәмәгать тәртибе, илнең икътисади тормыш дәрәҗәсе мәнфәгатьләрендә, тәртипсезлекләрне яки җинаятьләрне булдырмау, башка затларның сәламәтлеген яки әхлагын саклау яисә хокукларын һәм ирекләрен яклау максатларында кирәк булганда, гавами хакимиятләр тарафыннан бу хокукны гамәлгә ашыруга тыкшынуга юл куя.

Россия Федерациясе Конституциясенең 55 статьясындагы 3 өлеше мәгънәсе буенча хосусый тормыш хокукы шулай ук абсолют түгел һәм конституциячел төзелеш нигезләрен, башка затларның әхлаклылыгын, сәламәтлеген, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, илнең оборонасын һәм дәүләтнең иминлеген тәэмин итү максатларында кирәк булган кадәр генә чикләнергә мөмкин.

Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә гражданның сурәтен халыкка чыгару һәм киләчәктә дә кулланыга ризалыгы (шул исәптән ул сурәтләнгән видеоязмалар), сурәтне куллану дәүләт, җәмәгать яисә бүтән гавами мәнфәгатьләрдә гамәлгә ашырылган очракларда, теләсә кем йөри ала торган ачык урыннарда уздырыла торган чараларда төшерелгән граждан сурәтен куллануга ризалык таләп ителми, моңа сурәт төп куллану объекты булган очраклар керми (152.1 статьяның 1 пунктындагы 1 һәм 2 пунктчалары). Шул ук вакытта «"Массакүләм мәгълүмат чаралары турында" Россия Федерациясе законын судлар тарафыннан куллану практикасы турында» 2010 елның 15 июнендәге 16 номерлы Россия Федерациясе Югары Суды Пленумы карарындагы аңлатмалар нигезендә, иҗтимагый мәнфәгатьләргә аудитория тарафыннан күрсәтелгән теләсә нинди кызыксынуны түгел, ә, мәсәлән, җәмгыятьнең демократик хокукый дәүләткә һәм граждан җәмгыятенә, җәмәгать куркынычсызлыгына, әйләнә-тирә мохиткә куркыныч янавын ачыклау һәм ачу ихтыяҗын кертергә кирәк (25 пунктның өченче абзацы).

Дәгъва белдерелә торган 1 нче ярдәмче программада күрсәтелгәнчә, Казан шәһәренең торак фондында чаралар комплексын гамәлгә ашыру җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдә, хокук бозуларны профилактикалауда, террорчылыкка каршы торуда, экстремизмны профилактикалауда аерым юнәлеш булып тора. 1 нче ярдәмче программаның III бүлеге нигезләмәләре буенча видеокүзәтү, функциональ билгеләнеше буенча, видеокүзәтү объектын реаль вакыт режимында оператив контрольдә тотуга, архив видеоязмаларын җыю, саклау һәм таратуга һәм вакыйгаларга видеоанализ ясау, объектларны тануга бүленә. Шул ук вакытта, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый акт нигезләмәләренең турыдан-туры эчтәлегеннән күренгәнчә, реаль вакыт режимында видеосурәттән ерактан файдалану мөмкинлеге бары тик җәмәгать урыннарында, паркларда һәм скверларда, җәмәгатьчелек фикерен белдерү урыннарында, муниципаль

милектәге социаль өлкә объектларында урнаштырылган камералардан трансляцияләнүче видеосурәтләргә карата гына рөхсәт ителә.

Димәк, карала торган муниципаль программа нигезләмәләре үзенең хокукый мәгънәсе һәм эчтәлеге буенча күпфатирлы йортның уртак файдалану урыннарыннан читтә видеокүзәтү оештыруны, шулай ук чикләнмәгән затлар даирәсенең реаль вакыт режимында трансляцияләнә торган видеосурәтләргә үтемлелеген күз алдында тотмый.

Шулай итеп, видеокүзәтүне гамәлгә ашыруның максаты гражданнарның иминлеген тәэмин итү икәнлеген һәм үзеннән-үзе күпфатирлы йортлар территориясендә видеокүзәтүнең комплекслы системасын кертү мондый йортлардагы биналар милекчеләренең бу хакта турыдан-туры ихтыяр белдерүеннән башка мөмкин түгеллеген исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләрнең дә, дәгъва белдерелә торган нигезләмәләр белән аларның шәхси тормышының кагылгысызлыгына карата конституциячел хокуклары бозылган дип тапмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5251 номерлы карары белән расланган «2017—2019 елларга Казан шәһәрендә "Электрон Казан" мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне үстерү» муниципаль программасына 1 нче ярдәмче программаның III бүлегендәге аерым нигезләмәләрен, күрсәтелгән 1 нче ярдәмче программага кушымтаны, шулай ук аны кабул итү һәм рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча тулаем әлеге карарны Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге эштә Татарстан Республикасы Конституция суды «2017—2019 елларга Казан шәһәрендә "Электрон Казан" мәгълүмат технологияләрен һәм элемтәне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21 декабрендәге 5251 номерлы карарын аны кабул итү тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып кала.

Моның белән Казан шәһәренең җирле администрациясеннән, Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм әлеге Карарны исәпкә алып, муниципаль программаларны кабул итү срогы турындагы таләпнең үтәлешен чынлыкта тәэмин итү бурычы алынмый.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазифаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 86-П

Татарстан Республикасы
Конституция суды

ИМЕНЕМ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

25 декабря
2019 года
город Казань

**по делу о проверке конституционности абзаца второго подпункта «а» пункта 8 Правил выдачи, реализации сертификатов для обеспечения жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий, утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 16 мая 2008 года № 326 «О внесении изменений в постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 “О мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий”», в связи с жалобой гражданина А.В. Орлова**

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

руководствуясь статьей 109 (часть четвертая) Конституции Республики Татарстан, частями пятой и девятой статьи 3, частью первой и пунктом 1 части второй статьи 39, статьями 68, 83, 100, 101 и 103 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан»,

рассмотрел в открытом судебном заседании дело о проверке конституционности абзаца второго подпункта «а» пункта 8 Правил выдачи, реализации сертификатов для обеспечения жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий, утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 16 мая 2008 года № 326 «О внесении изменений в постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 “О мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий”».

Поводом к рассмотрению дела явилась жалоба гражданина А.В. Орлова. Основанием к рассмотрению дела явилась обнаружившаяся неопределенность в вопросе о том, соответствует ли оспариваемое заявителем нормативное положение Конституции Республики Татарстан.

Заслушав сообщение судьи-докладчика Э.М. Мустафиной, объяснения сторон — гражданина А.В. Орлова, представителя органа, издавшего оспариваемый нормативный правовой акт,— ведущего советника юридического отдела Министерства строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан Ф.М. Мухамадиевой, специалиста, приглашенного в судебное заседание по ходатайству представителя органа, издавшего оспариваемый нормативный правовой акт,— начальника отдела жилищной политики Министерства строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан Н.К. Вильдановой, выступления приглашенных в судебное заседание: представителя Президента Республики Татарстан — главного советника отдела по законопроектной работе Государственно-правового управления Президента Республики Татарстан Р.В. Сидакова, представителя Государственного

Совета Республики Татарстан — заместителя начальника Правового управления Аппарата Государственного Совета Республики Татарстан — заведующего отделом социального законодательства Правового управления Аппарата Государственного Совета Республики Татарстан Д.И. Махмутова, представителя Кабинета Министров Республики Татарстан — Правительства Республики Татарстан — начальника Правового управления Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан А.Б. Гревцова, представителя Председателя Верховного суда Республики Татарстан — судьи Верховного суда Республики Татарстан Э.С. Каминского, представителя Председателя Арбитражного суда Республики Татарстан — начальника отдела анализа и обобщения судебной практики Арбитражного суда Республики Татарстан Р.Р. Шкаликова, представителя Прокурора Республики Татарстан — начальника отдела по надзору за законностью нормативных правовых актов Управления по надзору за исполнением федерального законодательства прокуратуры Республики Татарстан А.Р. Валиахметова, представителя Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан — ведущего консультанта отдела по вопросам восстановления прав граждан аппарата Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан Р.Р. Мингалиева, исследовав представленные документы и иные материалы, Конституционный суд Республики Татарстан

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился гражданин А.В. Орлов с жалобой на нарушение его конституционных прав и свобод абзацем вторым подпункта «а» пункта 8 Правил выдачи, реализации сертификатов для обеспечения жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий, утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 16 мая 2008 года № 326 «О внесении изменений в постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 "О мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий"» (далее также — Правила).

Согласно обжалуемому абзацу второму подпункта «а» пункта 8 Правил в случае отчуждения многодетной семьей и (или) отдельными членами семьи жилого помещения (жилых помещений), принадлежащего им на праве собственности, либо принадлежащей указанным гражданам доли на праве общей совместной собственности на жилое помещение (далее — отчуждение многодетной семьей и (или) отдельными членами семьи принадлежащих им жилых помещений) размер общей площади жилого помещения, принимаемый для расчета размера субсидии, определяется как разница между общей площадью жилого помещения, установленной по нормативу, указанному в пункте 7 данных Правил, и суммарной общей площадью жилых помещений, занимаемых многодетной семьей по договорам социального найма, договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального ис-

пользования и (или) принадлежащих многодетной семье и (или) отдельным членам семьи на праве собственности (в случае, если занимаемые ими жилые помещения соответствуют санитарным нормам и правилам проживания), и отчужденного жилого помещения (доли в праве собственности на жилое помещение, приходящейся на отдельного члена семьи, установленной соглашением собственников жилого помещения или рассчитанной пропорционально их доле в праве общей собственности на жилое помещение); указанные гражданско-правовые сделки учитываются за период, предшествующий выдаче многодетной семье сертификата, но не менее чем за пять лет.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, гражданин А.В. Орлов указывает, что с 2013 года он с супругой и детьми состоят на учете в качестве нуждающихся в улучшении жилищных условий и, как многодетная семья, имеют право на получение сертификата, являющегося именным свидетельством, удостоверяющим право гражданина на получение за счет средств бюджета Республики Татарстан субсидии для приобретения жилого помещения (далее также — субсидия). В том же году заявитель продал принадлежавшую ему на праве собственности квартиру общей площадью 66,2 кв. метров.

При продаже квартиры он руководствовался действующим на тот период правовым регулированием, которое не содержало условия об учете совершенных гражданином гражданско-правовых сделок при исчислении размера названной субсидии. Гражданин А.В. Орлов отмечает, что обжалуемая норма была введена постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 27 июня 2016 года № 443. Однако при включении его семьи в список получателей жилищных сертификатов на 2018 год упомянутая сделка учтена правоприменительным органом при исчислении размера субсидии.

В этой связи, по его мнению, оспариваемая норма противоречит Конституции Республики Татарстан, поскольку по смыслу, придаваемому правоприменительной практикой, допускает ее применение к гражданам, совершившим гражданско-правовые сделки до вступления обжалуемой нормы в силу, то есть позволяет придавать обратную силу ее положениям, что недопустимо в условиях правового государства.

Заявитель также отмечает, что данная норма позволяет учитывать все гражданско-правовые сделки по отчуждению жилых помещений, то есть в том числе и те, которые не привели к ухудшению жилищных условий, а были совершены с целью улучшения жилищных условий.

Кроме того, гражданин А.В. Орлов усматривает неопределенность обжалуемой нормы в части предусмотренной в ней обязанности правоприменительного органа по учету гражданско-правовых сделок, предшествующих выдаче многодетной семье сертификата, за период не менее чем за пять лет. Так, он отмечает, что оспариваемая норма не устанавливает конкретный период, в течение которого учитывались бы гражданско-правовые

сделки, оставляя решение этого вопроса на усмотрение правоприменителя, который может учитывать данные сделки как за пять лет, так и за период свыше пяти лет.

На основании изложенного заявитель просит Конституционный суд Республики Татарстан признать абзац второй подпункта «а» пункта 8 Правил выдачи, реализации сертификатов для обеспечения жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий, утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 16 мая 2008 года № 326 «О внесении изменений в постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 "О мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий"», не соответствующим статьям 13, 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 38 (части первая и третья), 54 (часть первая), 55 Конституции Республики Татарстан согласно которым Республика Татарстан — социальное государство, политика которого направлена на создание условий, обеспечивающих достойную жизнь и свободное развитие человека; все равны перед законом и судом; государство гарантирует равенство прав и свобод человека и гражданина независимо от социального и имущественного положения и иных обстоятельств; любые формы ограничения прав и свобод либо установление преимуществ граждан по расовым, национальным и другим признакам запрещаются; семья, материнство, отцовство, детство и старость находятся под защитой государства; государство проявляет заботу о семье, обеспечении здоровья матери и ребенка и воспитании детей; каждому гарантируется социальное обеспечение для воспитания детей и в иных случаях, установленных законом; каждый имеет право на жилище; никто не может быть произвольно лишен жилища; органы государственной власти и органы местного самоуправления поощряют жилищное строительство, создают условия для осуществления права на жилище.

В соответствии с частями второй и третьей статьи 68 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан принимает решение по делу, оценивая как буквальный смысл рассматриваемого акта, так и смысл, придаваемый ему официальным и иным толкованием или сложившейся правоприменительной практикой, а также исходя из его места в системе нормативных правовых актов. Конституционный суд Республики Татарстан принимает постановление только по предмету, указанному в обращении, и лишь в отношении той части акта, конституционность которой подвергается сомнению в обращении, и при принятии решения не связан основаниями и доводами, изложенными в обращении.

Таким образом, предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан по настоящему делу является абзац второй подпункта «а» пункта 8 Правил выдачи, реализации сертификатов для обеспечения жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий, утвержденных поста-

новлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 16 мая 2008 года № 326 «О внесении изменений в постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 "О мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий"», в той мере, в какой он:

— по смыслу, придаваемому правоприменительной практикой, допускает возможность придания ему обратной силы и распространения его действия при расчете размера общей площади жилого помещения, принимаемого для определения размера субсидии, на гражданско-правовые сделки по отчуждению многодетной семьей и (или) отдельными членами семьи принадлежащих им жилых помещений, совершенные до вступления обжалуемой нормы в силу;

— позволяет учитывать гражданско-правовые сделки, совершенные многодетной семьей и (или) отдельными членами семьи по отчуждению принадлежащих им жилых помещений, в том числе и те, которые были совершены с целью улучшения жилищных условий, но не послужили при этом основанием для утраты нуждаемости в улучшении жилищных условий;

— не устанавливает конкретный период, в течение которого учитываются совершенные многодетной семьей и (или) отдельными членами семьи гражданско-правовые сделки по отчуждению принадлежащих им жилых помещений, при расчете размера общей площади жилого помещения, принимаемого для определения размера субсидии.

2. Оспариваемые заявителем правовые положения затрагивают сферы социальной защиты и жилищного законодательства. В соответствии со статьей 72 (пункты «ж» и «к» части 1) Конституции Российской Федерации социальная защита, включая социальное обеспечение, а также жилищное законодательство находятся в совместном ведении Российской Федерации и субъектов Российской Федерации. По предметам совместного ведения Российской Федерации и субъектов Российской Федерации издаются федеральные законы и принимаемые в соответствии с ними законы и иные нормативные правовые акты субъектов Российской Федерации; законы и иные нормативные правовые акты субъектов Российской Федерации не могут противоречить федеральным законам (статья 76, части 2 и 5 Конституции Российской Федерации).

В соответствии с подпунктом 24 пункта 2 статьи 26.3 Федерального закона от 6 октября 1999 года № 184-ФЗ «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации» решение вопросов социальной поддержки семей, имеющих детей (в том числе многодетных семей, одиноких родителей), относится к полномочиям органов государственной власти субъекта Российской Федерации по предметам совместного ведения, осуществляемым данными органами самостоятельно за счет средств бюджета субъекта Российской Федерации (за ис-

ключением субвенций из федерального бюджета). Также данным Федеральным законом предусмотрено, что органы государственной власти субъекта Российской Федерации вправе устанавливать за счет средств бюджета субъекта Российской Федерации (за исключением финансовых средств, передаваемых из федерального бюджета бюджету субъекта Российской Федерации на осуществление целевых расходов) дополнительные меры социальной поддержки и социальной помощи для отдельных категорий граждан вне зависимости от наличия в федеральных законах положений, устанавливающих указанное право. Финансирование названных полномочий не является обязанностью субъекта Российской Федерации, осуществляется при наличии возможности и не является основанием для выделения дополнительных средств из федерального бюджета (части третья и четвертая статьи 26.3-1).

Указом Президента Российской Федерации от 5 мая 1992 года № 431 «О мерах по социальной поддержке многодетных семей» правительствам республик в составе Российской Федерации, органам исполнительной власти краев, областей, автономных образований, городов Москва и Санкт-Петербург было поручено определить категории семей, которые относятся к многодетным и нуждаются в дополнительной социальной поддержке, с учетом национальных и культурных особенностей в социально-экономическом и демографическом развитии региона и установить для многодетных семей меры социальной поддержки (подпункты «а» и «б» пункта 1).

Указом Президента Республики Татарстан от 17 марта 2001 года № УП-216 «О дополнительных мерах по улучшению жилищных условий многодетных семей» установлено, что многодетные семьи, имеющие пять и более детей, проживающих с родителями и не образовавших свои семьи, нуждающиеся в улучшении жилищных условий, относятся к категориям граждан, имеющих право на внеочередное получение жилых помещений.

В развитие указанных нормативных правовых актов Кабинет Министров Республики Татарстан принял постановление от 18 декабря 2007 года № 732 «О мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий, детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, а также лиц из числа детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, не имеющих закрепленного за ними жилого помещения», в которое постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 16 мая 2008 года № 326 внесены изменения, а также утверждены оспариваемые Правила.

Таким образом, утверждая Правила выдачи, реализации сертификатов для обеспечения жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий, Кабинет Министров Республики Татарстан правомерно реализовал полномочие, принадлежащее ему в силу федерального и республиканского законодательства и основанное на взаимосвязанных положениях статей 102 (пункт 4) и 103 Конституции Республики Татарстан, согласно которым Кабинет Министров Республики Татарстан участвует в

проведении единой государственной политики в области социального обеспечения, обеспечивает исполнение на территории Республики Татарстан федеральных законов и иных нормативных правовых актов Российской Федерации, законов и иных нормативных правовых актов Республики Татарстан, издает постановления и распоряжения, которые обязательны к исполнению на всей территории Республики Татарстан.

3. Конституция Республики Татарстан, провозглашая Республику Татарстан социальным государством (статья 13), закрепляет, что семья, материнство и детство находятся под защитой государства, государство проявляет заботу о семье, обеспечении здоровья матери и ребенка и воспитании детей (статья 38, части первая и третья); каждому гарантируется социальное обеспечение для воспитания детей и в иных случаях, установленных законом (статья 54, часть первая). Аналогичные по смыслу гарантии установлены Конституцией Российской Федерации, в том числе ее статьями 7, 38 (часть 1) и 39 (часть 1).

Как отмечается в решениях Конституционного Суда Российской Федерации, относя социальную защиту, включая социальное обеспечение, к совместному ведению Российской Федерации и ее субъектов (статья 72, пункт «ж» части 1), Конституция Российской Федерации не устанавливает конкретные способы и объемы такой защиты, предоставляемой тем или иным категориям граждан. Решение этих вопросов является прерогативой законодателя, который при определении гарантий реализации прав, закрепленных статьями 38 и 39 Конституции Российской Федерации, располагает достаточно широкой свободой усмотрения в выборе мер социальной защиты семьи и детей, критериев их дифференциации, регламентации условий и порядка предоставления; он вправе также избирать и изменять формы (способы) их предоставления (Постановление от 10 ноября 2009 года № 17-П, Определение от 9 ноября 2010 года № 1439-О-О).

Мера социальной поддержки в виде предоставления на безвозмездной основе субсидии для приобретения жилья за счет средств бюджета Республики Татарстан установлена Кабинетом Министров Республики Татарстан в целях оказания дополнительной поддержки по обеспечению жильем нуждающихся в улучшении жилищных условий многодетных семей, имеющих пять и более детей, проживающих с родителями и не образовавших свои семьи (к детям многодетной семьи, образовавшим свои семьи, относятся совершеннолетние дети, состоящие в браке или имеющие своего ребенка (детей)) (подпункт «а» пункта 4 Правил).

По своей правовой природе данная мера социальной поддержки, как ранее отмечал Конституционный суд Республики Татарстан, не относится к обязательным видам социального обеспечения и, по существу, выступает в качестве дополнительного способа повышения уровня жизни указанных семей; Республика Татарстан самостоятельно определяет условия и порядок предоставления субсидии для обеспечения жильем многодетных семей, принимая во внимание в том числе и возможности бюджета

республики (постановления от 5 октября 2011 года № 44-П, от 30 мая 2019 года № 83-П, определение от 11 октября 2011 года № 13-О).

3.1. Кабинет Министров Республики Татарстан, регулируя вопрос предоставления дополнительной меры социальной поддержки многодетным семьям, обладает значительной дискрецией, которая, однако, ограничена конституционными принципами равенства, справедливости и соразмерности ограничения прав и свобод, требованиями определенности правового регулирования, в том числе в порождаемых им правовых последствиях, а также общими межотраслевыми правовыми принципами, одним из которых является принцип действия нормативного правового акта во времени.

Конституционный Суд Российской Федерации в своих решениях неоднократно указывал, что общим (основным) принципом действия закона во времени является распространение его на отношения, возникшие после введения его в действие, и только законодатель вправе распространить новые нормы на факты и порожденные ими правовые последствия, которые возникли до введения соответствующих норм в действие, т.е. придать закону обратную силу. При этом установление правил действия во времени и по кругу лиц новых норм, закрепляющих либо изменяющих права граждан, предусматривающих для них гарантии и льготы, должно осуществляться им с соблюдением требований Конституции Российской Федерации, в том числе вытекающих из принципа равенства (статья 19, части 1 и 2), который гарантирует гражданам защиту от всех форм дискриминации при реализации прав и свобод, включая право на социальное обеспечение (определения от 18 января 2005 года № 7-О; от 19 декабря 2017 года № 2978-О, от 26 марта 2019 года № 732-О и др.).

В силу положений статьи 6 Жилищного кодекса Российской Федерации акты жилищного законодательства не имеют обратной силы и применяются к жилищным отношениям, возникшим после введения его в действие (часть 1); действие акта жилищного законодательства может распространяться на жилищные отношения, возникшие до введения его в действие, только в случаях, прямо предусмотренных этим актом (часть 2).

Приведенное правовое регулирование применимо и к отношениям, складывающимся в сфере реализации многодетными семьями, нуждающимися в улучшении жилищных условий, права на получение субсидии для приобретения жилья.

Постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 27 июня 2016 года № 443 подпункт «а» пункта 8 Правил был дополнен оспариваемым абзацем, предусматривающим изменение порядка расчета размера общей площади жилого помещения, принимаемого для определения размера субсидии. В соответствии с данными изменениями при определении размера субсидии стали подлежать учету все гражданско-правовые сделки по отчуждению многодетной семьей и (или) отдельным членами семьи жилых помещений, принадлежащих им на праве собствен-

ности, за период, предшествующий выдаче многодетной семье сертификата, но не менее чем за пять лет.

Между тем, из анализа содержания постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 27 июня 2016 года № 443, которым введена оспариваемая норма, следует, что оно не устанавливает положения о распространении нового правового регулирования на правоотношения, возникшие до вступления его в силу.

общественного туалета, расположенного в границах объекта культурного наследия регионального (республиканского) значения «Городской сад “Черное озеро”, нач. XIX в.», возможна только в рамках работ по его сохранению на основании письменного задания и разрешения Министерства культуры Республики Татарстан, которое выдается после согласования указанным Министерством проектной документации, получившей положительное заключение государственной историко-культурной экспертизы. Гражданке Г.С. Рахматуллиной было выдано соответствующее письменное задание и разрешение на перепрофилирование только под общественный туалет.

По мнению заявительницы, Федеральным законом от 25 июня 2002 года № 73-ФЗ «Об объектах культурного наследия (памятниках истории и культуры) народов Российской Федерации» (далее также — Федеральный закон) четко определено, что разрешается и что запрещается осуществлять в границах территории объекта культурного наследия. Она полагает, что Федеральный закон не предоставляет субъектам Российской Федерации полномочий по определению видов хозяйственной деятельности, которые разрешены осуществлять в границах территории объекта культурного наследия, поскольку этот вопрос уже полностью урегулирован в главе VII этого закона, поэтому Кабинет Министров Республики Татарстан, принимая оспариваемые нормы, вторгся в компетенцию федерального законодателя.

На основании изложенного гражданка Г.С. Рахматуллина считает, что обжалуемые положения нарушают права собственников и препятствуют выбору экономической деятельности. В связи с этим она просит Конституционный суд Республики Татарстан признать абзацы первый—двенадцатый и пятнадцатый Режима использования территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в городе Казани, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 апреля 2013 года № 266 «Об утверждении границ территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, и режима их использования» не соответствующими статьям 18 (часть первая), 19 (часть первая), 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая) и 49 Конституции Республики Татарстан.

2. Правовое регулирование отношений в области сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия (памятников истории и культуры) народов Российской Федерации осуществляется в соответствии с Федеральным законом от 25 июня 2002 года № 73-ФЗ «Об объектах культурного наследия (памятниках истории и культуры) народов Российской Федерации» и принимаемыми в соответствии с ним другими федеральными законами, а также законами субъектов Российской Федерации в области государственной охраны объектов культурного наследия (статья 2).

В Республике Татарстан эти правоотношения регулирует Закон Республики Татарстан от 1 апреля 2005 года № 60-ЗРТ «Об объек-

тах культурного наследия в Республике Татарстан» (далее также — Закон Республики Татарстан). В соответствии с пунктом 6 статьи 6 и пунктом 3 статьи 25 данного Закона Республики Татарстан (в редакции, действовавшей до вступления в силу Закона Республики Татарстан от 2 июля 2015 года № 51-ЗРТ) к полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан было отнесено установление и утверждение границ зон охраны объектов культурного наследия, режимов использования территории объекта культурного наследия регионального (республиканского) значения. Указанное полномочие в свою очередь было основано на Федеральном законе (в редакции, действовавшей до вступления в силу Федерального закона от 3 августа 2018 года № 324-ФЗ), согласно которому к ведению органов государственной власти субъекта Российской Федерации в области сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия регионального значения отнесено утверждение границ зоны охраны объектов культурного наследия, особых режимов использования земель в границах территорий данных зон.

В рамках реализации предоставленных полномочий оспариваемым постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан № 266 были утверждены границы территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в городе Казани, в том числе границы территории объекта культурного наследия регионального значения «Городской сад “Черное озеро”, нач. XIX в.» (пункт 22). Данный объект является объектом культурного наследия регионального значения в соответствии с постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 10 ноября 2002 года № 626 «О включении в государственные охранные реестры недвижимых памятников истории, градостроительства и архитектуры республиканского (Республики Татарстан) значения дополнительно выявленных объектов».

Конституционный Суд Российской Федерации отметил, что объект культурного наследия имеет исторические и культурные особенности (предмет охраны), которые обусловливают его особую защиту, обеспечиваемую как за счет ограничительных законодательных требований, связанных с функционированием данных объектов и прилегающей к ним территории, так и за счет законодательных требований, непосредственно направленных на проведение работ по сохранению этих объектов, включая их консервацию, ремонт, реставрацию и приспособление для современного использования (Определение от 18 июля 2017 года № 1654-О). Указанные требования нашли свое отражение в статьях 5.1 (подпункт 1 пункта 1), 35, 40 (пункт 3), 41, 44, 45, 47 и других предписаниях этого Федерального закона. Аналогичные по своему содержанию и правовому смыслу положения были установлены статьей 35 Федерального закона (действовавшей в редакции до вступления в силу Федерального закона от 22 октября 2014 года № 315-ФЗ).

Утвержденный оспариваемым постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан № 266 режим использования территорий объектов культурного наследия регионального (республи-

канского) значения предусматривает ограничение хозяйственной деятельности и иные требования, необходимые для обеспечения сохранности объекта культурного наследия. Данные требования установлены не произвольно, а основаны на положениях Федерального закона, подпунктом 3 пункта 1 статьи 5.1 которого органу исполнительной власти субъекта Российской Федерации предоставлено право устанавливать требования к осуществлению деятельности в границах территории объекта культурного наследия.

Таким образом, обжалуемые положения режима использования территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в городе Казани, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан № 266, по существу воспроизводят нормы Федерального закона «Об объектах культурного наследия (памятниках истории и культуры) народов Российской Федерации» и не превышают требования и ограничения, закрепленные Федеральным законом. Следовательно, Кабинет Министров Республики Татарстан при принятии постановления от 18 апреля 2013 года № 266 «Об утверждении границ территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, и режима их использования» не вышел за пределы полномочий, предоставленных органам государственной власти субъектов Российской Федерации при регулировании отношений в области сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия.

В связи с этим оспариваемые гражданкой Г.С. Рахматуллиной абзацы первый—двенадцатый и пятнадцатый Режима использования территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в городе Казани, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 апреля 2013 года № 266 «Об утверждении границ территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, и режима их использования», сами по себе не содержат неопределенности в вопросе их соответствия Конституции Республики Татарстан и согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» данная жалоба не является допустимой.

На основании изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.С. Рахматуллиной на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацами первым—двенадцатым и пятнадцатым Режи-

ма использования территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в городе Казани, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 апреля 2013 года № 266 «Об утверждении границ территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, и режима их использования», поскольку она в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.С. Рахматуллиной и в Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан» и на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU).

№ 33-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫныңың

**«Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 апрелендәге 266 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимының беренче—уникенче һәм унбишенче абзацлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.С. Рәхмәтуллина шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2019 ел
30 октябрь
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.С. Рәхмәтуллина шикаятен алдан өйрәнгән судья Ф.Р. Волкова бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**а ч ы к л а д ы :**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.С. Рәхмәтуллина «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 апрелендәге 266 номерлы карары (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 266 номерлы карары) белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимының беренче—уникенче һәм унбишенче абзацлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте. Дәгъва белдерелә торган нормалар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 266 номерлы карары белән расланган төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрендә башкарырга рөхсәт ителгән эш төрләрен, шулай ук бу эшләрне башкару тәртибен билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушып бирелгән документларның күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче «“Черек күл” шәһәр бакчасы, XIX гасыр башы» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең 1/2 өлешенең һәм әлеге җир кишәрлегендә урнашкан җәмәгать бәдрәфе бинасының 1/2 өлешенең милекчесе булып тора. Күрсәтелгән бинаның җәмәгать туклануы объекты итеп үзгәртелүенә бәйле рәвештә, җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү максатында ул Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма

комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына мөрәҗәгать иткән. Аның мөрәҗәгатьләренә әлеге органнарның җаваплары эчтәлегеннән аңлашылганча, «“Черек күл” шәһәр бакчасы, XIX гасыр башы» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә урнашкан җәмәгать бәдрәфе бинасын реконструкцияләү бары тик аны саклау буенча башкарыла торган эшләр кысаларында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының язма биреме һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсен алган проект документациясен күрсәтелгән министрлык белән килештергәннән соң бирелә торган рөхсәте нигезендә генә мөмкин. Гражданка Г.С. Рәхмәтуллинага тиешле язма бирем һәм яңадан бары тик җәмәгать бәдрәфе итеп үзгәртүгә генә рөхсәт бирелгән.

Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба шулай ук — Федераль закон) мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә нәрсә рөхсәт ителүе һәм нәрсә тыелуы төгәл билгеләнгән. Ул, Федераль закон Россия Федерациясе субъектларына мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә гамәлгә ашырырга рөхсәт ителгән хуҗалык эшчәнлеге төрләрен билгеләү буенча вәкаләтләр бирми, чөнки бу мәсьәлә әлеге законның VII бүлегендә инде тулысынча җайга салынган, шуңа күрә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, дәгъва белдерелә торган нормаларны кабул итеп, федераль закон чыгаручы компетенциясенә кергән, дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданка Г.С. Рәхмәтуллина фикеренчә, шикаять бирелә торган нигезләмәләр милекчеләрнең хокукларын боза һәм аларның икътисадый эшчәнлек төрен сайлавына комачаулый. Шуңа бәйле рәвештә ул Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 апрелендәге 266 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимының беренче—уникенче һәм унбишенче абзацларын Татарстан Республикасы Конституциясенең 18 (беренче өлеш), 19 (беренче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон һәм аның нигезендә кабул ителә торган башка феде-

раль законнар, шулай ук мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә гамәлгә ашырыла (2 статья).

Татарстан Республикасында бу хокукый мөнәсәбәтләрне «Татарстан Республикасындагы мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) җайга сала. Әлеге Татарстан Республикасы Законының (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергәнче гамәлдә булган редакциясендә) 6 статьясындагы 6 пункты һәм 25 статьясындагы 3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә мәдәни мирас объектларын саклау зоналары чикләрен, төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимнарын билгеләү һәм раслау кертелгән иде. Әлеге вәкаләт, үз чиратында, Федераль законга (2018 елның 3 августындагы 324-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергәнче гамәлдә булган редакциясендә) нигезләнгән иде, аның нигезендә төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнары карамагына мәдәни мирас объектларын саклау зонасы чикләрен, әлеге зоналар территорияләре чикләрендә җирләрне файдалануның махсус режимнарын раслау кертелгән.

Бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъва белдерелә торган 266 номерлы карары белән Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимы, шул исәптән «“Черек күл” шәһәр бакчасы, XIX гасыр башы» төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре расланган (22 пункт). Әлеге объект «Республика (Татарстан Республикасы) әһәмиятендәге тарихи, шәһәр төзелеше һәм архитектура күчемсез һәйкәлләренең дәүләт саклау реестрына өстәмә ачыкланган объектларны кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 елның 10 ноябрендәге 626 номерлы карары нигезендә төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты булып тора.

Россия Федерациясе Конституция Суды мәдәни мирас объектының тарихи һәм мәдәни үзенчәлекләргә (саклау предметы) ия булуын, әлеге объектларның һәм алар янәшәсендәге территорияләрнең эшләвенә бәйле чикләү закон таләпләре хисабына тәэмин ителә торган, шулай ук әлеге объектларны саклау буенча эшләрне башкаруга турыдан-туры юнәлдерелгән закон таләпләре хисабына да, аларны черүдән саклау, ремонтлау, реставрацияләү эшләрен һәм заманча куллану өчен җайланмаларны да кертеп, аерым яклауга бәйле булуын билгеләп үтте (2017 елның 18 июлендәге 1654-О номерлы Билгеләмә). Күрсәтелгән таләпләр 5.1 (1 пунктның 1 пунктчасы), 35, 40 (3 пункт), 41, 44, 45, 47 статьяларында һәм бу Федераль законның башка күрсәтмәләрендә үз чагылышын тапкан. Эчтәлеге һәм хокукый мәгънәсе буенча

шундый ук нигезләмәләр Федераль законның (2014 елның 22 октябрендәге 315-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергәнче гамәлдә булган редакциясендә) 35 статьясы белән билгеләнгән иде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъва белдерелә торган 266 номерлы карары белән расланган төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимы хуҗалык эшчәнлеген чикләүне һәм мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү өчен кирәкле башка таләпләрне күздә тота. Әлеге таләпләр нигезсез билгеләнмәгән, ә 5.1 статьяның 1 пунктындагы 3 пунктчасы белән Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органына мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру таләпләрен билгеләү хокукы бирелгән Федераль закон нигезләмәләренә таянган.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 266 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимының шикаять белдерелә торган нигезләмәләре асылда «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» Федераль закон нормаларын кабатлыйлар һәм Федераль закон белән билгеләнгән таләпләрне һәм чикләүләрне арттырмыйлар. Димәк, «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» 2013 елның 18 апрелендәге 266 номерлы карарын кабул иткәндә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салганда Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына бирелгән вәкаләтләрдән читкә чыкмаган.

Шуңа бәйле рәвештә гражданка Г.С. Рәхмәтуллина тарафыннан дәгъва белдерелә торган «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 апрелендәге 266 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимының беренче—уникенче һәм унбишенче абзацларының үзеннән-үзе Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә әлеге шикаять карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 ста-

тьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 апрелендәге 266 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимының беренче—уникенче һәм унбишенче абзацлары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.С. Рәхмәтуллина шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.С. Рәхмәтуллинага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

№ 33-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

30 октября
2019 года
город Казань

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.С. Рахматуллиной на нарушение ее конституционных прав и свобод частями 1 и 3 статьи 3 Закона Республики Татарстан от 1 апреля 2005 года № 60-ЗРТ «Об объектах культурного наследия в Республике Татарстан»**

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Л.В. Кузьминой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Г.С. Рахматуллиной,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Г.С. Рахматуллина с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод частями 1 и 3 статьи 3 Закона Республики Татарстан от 1 апреля 2005 года № 60-ЗРТ «Об объектах культурного наследия в Республике Татарстан» (далее также — Закон Республики Татарстан).

Оспариваемыми положениями статьи 3 Закона Республики Татарстан определены полномочия Государственного Совета Республики Татарстан и Кабинета Министров Республики Татарстан в области сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия в Республике Татарстан.

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что заявительница является собственником 1/2 доли земельного участка, расположенного в границах территории объекта культурного наследия регионального (республиканского) значения «Городской сад “Черное озеро”, нач. XIX в.», и 1/2 доли находящегося на данном земельном участке здания общественного туалета. С целью изменения вида разрешенного использования земельного участка в связи с реконструкцией указанного здания в объект общественного питания она обратилась в Управление архитектуры и градостроительства Исполнительного комитета муниципального образования города Казани, а также в Исполнительный комитет муниципального образования города Казани и в Министерство культуры Республики Татарстан. В ответах вышеназванных органов на ее обращения отмечается, что реконструкция здания общественного туалета, расположенного в границах территории объекта культурного наследия регионального (республиканского) значения «Городской сад “Черное озеро”, нач. XIX в.», возможна только в рамках работ по его сохранению на основании письменного задания и разрешения Министерства культуры Республики Татарстан. Письменное разрешение выдается на основании согласованной указанным Министерством проектной документации, получившей положительное заключение государственной

историко-культурной экспертизы. Проектной документацией на проведение работ по реставрации и приспособлению для современного использования объекта культурного наследия предусмотрен ремонт здания общественного туалета с соответствующим видом разрешенного использования.

Гражданка Г.С. Рахматуллина подчеркивает, что оспариваемая часть 3 статьи 3 Закона Республики Татарстан к полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан в области сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия установление режима использования территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения не относит. Вместе с тем, согласно пункту 1 части 1 статьи 3 Закона Республики Татарстан к полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан отнесено законодательное регулирование отношений в области сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия. Как полагает заявительница, установление режима использования территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения является регулированием отношений в области сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия и, следовательно, относится к полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан. Утверждение же режима использования территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в городе Казани, постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан, по ее утверждению, свидетельствует о наличии неопределенности в оспариваемых положениях в части разграничения полномочий Государственного Совета Республики Татарстан и Кабинета Министров Республики Татарстан.

В этой связи она отмечает, что особая процедура принятия и внесения изменений в законодательные акты, в отличие от процедуры принятия и внесения изменений в решения Кабинета Министров Республики Татарстан, повышает уровень правовой защищенности граждан при регулировании соответствующих вопросов на законодательном уровне. Это, по ее мнению, связано с публичным характером принятия законов лицами, наделенными особым статусом и доверием избирателей.

Таким образом, гражданка Г.С. Рахматуллина считает, что обжалуемые нормы Закона Республики Татарстан нарушают ее конституционные права и не отвечают конституционному принципу правовой определенности, в связи с чем она просит признать части 1 и 3 статьи 3 Закона Республики Татарстан от 1 апреля 2005 года № 60-ЗРТ «Об объектах культурного наследия в Республике Татарстан» не соответствующими статьям 18 (часть 1), 19 (часть 1), 28 (части 1 и 2), 29 (часть 1), 49 Конституции Республики Татарстан.

2. Отношения в области сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия (памятников истории и культуры) народов Российской Федерации

регулирует Федеральный закон от 25 июня 2002 года № 73-ФЗ «Об объектах культурного наследия (памятниках истории и культуры) народов Российской Федерации» (далее также — Федеральный закон). В силу статьи 9.2 указанного Федерального закона к полномочиям органов государственной власти субъекта Российской Федерации в области сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия отнесено, в том числе, принятие законов и иных нормативных правовых актов субъекта Российской Федерации в пределах полномочий органов государственной власти субъекта Российской Федерации и контроль за их исполнением, а также иные полномочия, предусмотренные данным Федеральным законом и иными федеральными законами, а также законами субъектов Российской Федерации.

Во исполнение положений Федерального закона в Республике Татарстан вопросы сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия (памятников истории и культуры) народов Российской Федерации в Республике Татарстан урегулированы оспариваемым Законом Республики Татарстан, которым в обжалуемых нормах определены полномочия Государственного Совета Республики Татарстан и Кабинета Министров Республики Татарстан в области сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия. При этом полномочия по утверждению Кабинетом Министров Республики Татарстан границ, режимов охраны и использования территории объекта культурного наследия регионального (республиканского) или местного (муниципального) значения были предусмотрены пунктом 3 статьи 25 Закона Республики Татарстан в редакции от 11 марта 2013 года, действующей на момент принятия постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 апреля 2013 года № 266 «Об утверждении границ территорий объектов культурного наследия регионального (республиканского) значения, расположенных в г. Казани, и режима их использования».

Таким образом, оспариваемое правовое регулирование принято Государственным Советом Республики Татарстан в пределах своих дискреционных полномочий, предоставленных федеральным законодательством в области сохранения, использования, популяризации и государственной охраны объектов культурного наследия в Республике Татарстан, а также основано на положениях статьи 75 (пункт 2) Конституции Республики Татарстан, согласно которым законодательное регулирование по предметам совместного ведения Российской Федерации и ее субъектов в пределах полномочий Республики Татарстан осуществляется Государственным Советом Республики Татарстан. Обжалуемые нормы сами по себе не могут рассматриваться как нарушающие конституционные права и свободы человека и гражданина, в том числе заявительницы, и, следовательно, не содержат неопределенности в вопросе об их соответствии Конституции Республики Татарстан. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан

«О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба гражданки Г.С. Рахматуллиной не является допустимой.

Внесение же целесообразных, с точки зрения заявительницы, изменений в оспариваемое правовое регулирование не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктом 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73, 100 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.С. Рахматуллиной на нарушение ее конституционных прав и свобод частями 1 и 3 статьи 3 Закона Республики Татарстан от 1 апреля 2005 года № 60-ЗРТ «Об объектах культурного наследия в Республике Татарстан», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение поставленного заявительницей вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.С. Рахматуллиной и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан» и на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU).

№ 34-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫныңың

**«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 һәм 3 өлешләре белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.С. Рәхмәтуллина шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2019 ел
30 октябрь
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.С. Рәхмәтуллина шикаятен алдан өйрәнгән судья Л.В. Кузьмина бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**а ч ы к л а д ы :**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.С. Рәхмәтуллина «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) 3 статьясындагы 1 һәм 3 өлешләре белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы дәгъва белдерелә торган нигезләмәләрдә Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре билгеләнгән.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәжәгать итүче «“Черек күл” шәһәр бакчасы, XIX гасыр башы» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең 1/2 өлешенең һәм әлеге җир кишәрлегендә урнашкан җәмәгать бәдрәфе бинасының 1/2 өлешенең милекчесе булып тора. Күрсәтелгән бинаның җәмәгать туклануы объекты итеп үзгәртелүенә бәйле рәвештә, җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү максатында ул Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына мөрәҗәгать иткән. Югарыда аталган органнарның аның мөрәҗәгатьләренә җавапларында «“Черек күл” шәһәр бакчасы, XIX гасыр башы» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә урнашкан җәмәгать

бәдрәфе бинасын реконструкцияләү бары тик аны саклау буенча башкарыла торган эшләр кысаларында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының язма биреме һәм рөхсәте нигезендә генә мөмкин дип билгеләп үтелә. Дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсен алган проект документларын күрсәтелгән Министрлык белән килештерү нигезендә язмача рөхсәт бирелә. Мәдәни мирас объектыннан заманча файдалану өчен реставрация һәм җайлаштыру эшләрен башкару буенча проект документларында файдалануның рөхсәт ителгән тиешле төре белән җәмәгать бәдрәфе бинасын ремонтлау каралган.

Гражданка Г.С. Рәхмәтуллина Татарстан Республикасы Законының дәгъва белдерелә торган 3 статьясындагы 3 өлеше мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимын билгеләүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә кертми дип ассызыклый. Шуның белән бергә, Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты нигезендә мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә кертелгән. Мөрәҗәгать итүче төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимын билгеләү мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салу булып тора һәм, димәк, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә керә дип саный. Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслау, аның фикеренчә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләрен чикләү өлешендә дәгъва белдерелә торган нигезләмәләрдә билгесезлек булуны күрсәтә.

Шуңа бәйле рәвештә ул, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын кабул итү һәм аларга үзгәрешләр кертү процедурасыннан аермалы буларак, закон актларын кабул итү һәм аларга үзгәрешләр кертүнең махсус процедурасы закон дәрәҗәсендә тиешле мәсьәләләрне җайга салганда гражданнарның хокукый якланганлыгы дәрәҗәсен арттыра дип билгеләп үтә. Бу, аның фикеренчә, сайлаучылар ышанычына һәм аерым статуска ия булган затлар тарафыннан законнар кабул итүнең гавами характеры белән бәйле.

Шулай итеп, гражданка Г.С. Рәхмәтуллина Татарстан Республикасы Законының шикаять белдерелә торган нормалары аның конституциячел хокукларын боза һәм хокукый билгеләнешнең конституциячел принцибына туры килми дип саный, шуңа

бәйле рәвештә ул «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 һәм 3 өлешләрен Татарстан Республикасы Конституциясенең 18 (1 өлеш), 19 (1 өлеш), 28 (1 һәм 2 өлешләр), 29 (1 өлеш), 49 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

1. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба шулай ук — Федераль закон) җайга сала. Күрсәтелгән Федераль законның 9.2 статьясы нигезендә мәдәни мирас объектларын саклау, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләренә, шул исәптән, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре карамагындагы Россия Федерациясе субъектына кагылышлы законнар һәм башка төр норматив-хокукый актлар кабул итү һәм аларның үтәлешен контрольдә тоту, шулай ук әлеге Федераль законда һәм башка федераль законнарда, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган башка вәкаләтләр кертелгән.

Федераль закон нигезләмәләрен үтәү йөзеннән Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге мәсьәләләр Татарстан Республикасында дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законы белән җайга салынган, аның белән дәгъва белдерелә торган нормаларда мәдәни мирас объектларын саклау, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре билгеләнгән. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төбәк (республика) яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен раслау, саклау һәм алардан файдалану режимын раслау буенча вәкаләтләр «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» 2013 елның 18 апрелендәге 266 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителгән вакытка гамәлдә булган Татарстан Республикасы Законының 25 статьясындагы 3 пункты белән 2013 елның 11 мартындагы редакциясендә каралган иде.

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган хокукый җайга салу Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларын саклап калу,

алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә федераль законнар белән үзенең дискрецион вәкаләтләре кысаларында кабул ителгән, шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы (2 пункт) нигезләмәләренә таянган, алар нигезендә Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләрне Татарстан Республикасы вәкаләтләре чикләрендә закон чыгарып җайга салу Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Шикаять белдерелә торган нормалар үзеннән-үзе кеше һәм гражданның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза торган буларак карала алмый һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы мәсьәләдә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә гражданка Г.С. Рәхмәтуллинаның шикаяте карала алмый.

Мөрәҗәгать итүче күзлегеннән чыгып, дәгъва белдерелә торган хокукый җайга салуга максатка ярашлы үзгәрешләр кертү Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73, 100 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 һәм 3 өлешләре белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.С. Рәхмәтуллина шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.С. Рәхмәтуллинага һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

№ 34-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# РАЗДЕЛ II.

# ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# ИНФОРМАЦИЯ
# О IV КОНСТИТУЦИОННЫХ ЧТЕНИЯХ
# РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

25 октября в 10.00 в Большом конференц-зале ГАУ «Технопарк в сфере высоких технологий “ИТ-парк”» состоялись IV Конституционные чтения Республики Татарстан на тему: **«Создание единого информационного пространства: конституционно-правовые аспекты»**. Конференция была организована Конституционным судом Республики Татарстан при содействии Министерства цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан.

В состав Президиума входили председательствующий Ю.З. Камалтынов, заместитель Председателя Государственного Совета Республики Татарстан; члены Президиума: Ф.Г. Хуснутдинов, Председатель Конституционного суда Республики Татарстан; И.И. Гилазов, Председатель Верховного суда Республики Татарстан; А.Р. Мугинов, заместитель министра цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан.

В работе Конституционных чтений помимо действующего состава судей Конституционного суда Республики Татарстан и судей в отставке приняли участие представители органов государственной власти, научного сообщества и институтов гражданского общества.

Открывая заседание, заместитель Председателя Государственного Совета Республики Татарстан Ю.З. Камалтынов поприветствовал участников конференции, рассказал о ее целях и задачах и озвучил вопросы, подлежащие обсуждению. Далее Ю.З. Камалтынов зачитал приветственное слово Председателя Государственного Совета Республики Татарстан Ф.Х. Мухаметшина, в котором была отмечена значимость проведения Конституционных чтений Республики Татарстан.

